СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.


**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**19 октябрь 2020 ел. N 4**

**Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Венета авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Венета авылында, Венета авылы, Мәктәп урамы, 3 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 05 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыены билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Венета авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Венета авылына су башнясы сатып алу һәм урнаштыру.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

3. Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Венета авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы Венета авылы, Мәктәп урамы, 3 йорт адресы

буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Һидиятуллин